# *“Туган як  ономастикасы.Тау ягы ялгызлык исемнәре”*

# *проекты*

***Төзүче:  Яшел Үзән муниципаль районы***

***муниципаль бюджет  белем бирү учреждениесе***

***5нче гимназиясенең***

***югары квалификацион  категорияле***

***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

***Сәләхова Зөлфирә Үрнәк кызы***

# Аңлатма язуы

Татар әдәби теле - һәрьяклап камилләшкән милли телләрнең берсе. Тел белеменең бүлекләре фәнни яктан тулы эшкәртелгән. Дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларда җирле материаллар кертү, өйрәнү өлкәсендә шулай ук нәтиҗәле эшләр башкарыла. Шул исәптән, югары сыйныф укучылары белән фәнни-тикшеренү эшләрен оештыру балаларның бай мәгълумат үзләштерүен тәэмин итә. Лексикологиянең бер бүлеге - ономастика укучыларда шактый зур кызыксыну уята, төбәк топонимнарын өйрәнү киләчәктә10 - 11 сыйныфта "Татар топонимикасы" бүлеген тирәнтен үзләштерү өчен җирлек тә булып тора. Өстәвенә, авыл атамалары, микротопоним, гидроним, ойконимнар безнең борынгы тарихыбызны, данлы үткәнебезне билгели. Үзенең туган телен, тарихын, мәдәниятен, туган җирен белеп үскән бала гына киң карашлы, тирән белемле шәхес булып формалаша ала. Халык тарихын, мәдәниятен, мәгарифен өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү туган як, туган җир, туган авыл, аның тарихын, язмышын, күренекле шәхесләрен өйрәнүдән башлана. Әлеге проектның төп максаты: антропонимика, топонимика, гидронимика, ойкономика бүлекләренә караган , тау ягында киң таралган ялгызлык исемнәрен өйрәнү.

“Антропонимика” бүлеге түбәндәге бурычларны үтәүне күз алдында тота. Татар халкы элек-электән балага исем исем кушуга бик җаваплы караган, исемнең кеше язмышынада турыдан- туры әһәмияткә ия булуына бершиксез ышанган. Исемнең җисеменә туры килүен теләгән, шунлыктан үз баласына тирән мәгънәгә ия булган исемнәрне генә куша.

Исем - фамилия милләтнең йөзе, тылсымлы могҗизасы һәм сакчысы, һәркемгә үз исеме - күңеленә иң якын, иң кадерле исем- сүз. Хәзерге вакытта исем кушу йолаларының ничек үтәлә, Тау ягы төбәгендәге аерым авылларда нинди исемнәргә ныграк игътибар бирелә. Укучылар әлеге сорауларга җавап табарга тырыша. Шулай ук зур авылларда һәр нәселнең үз кушаматы булуы-гадәти күренеш. Үз нәселенә хас булган кушаматларның тарихын укучылар бик теләп өйрәнә, шунлыктан аларга кыска вакытлы эзләнү- тикшеренү эшләре

тәкъдим ителә. Киләчәк буыннарның милли йөзен саклап калуга өлеш кертү - кирәкле эш.

Топонимика буенча материал мәктәптә алган белемнәргә, җирле - төбәк күрсәткечләргә нигезләнеп төзелде. Микротопонимнарны җыю, өйрәнү, фәнни чыганакларга таянып, чагыштырулар, нәтиҗәләр ясау; аларны лингвистик яссылыкта анализлауга, практик эшчәнлеккә күп урын бирелде.

Шулай итеп, проект түбәндәге **максатларны** күздә тотып төзелде:

- “Ономастика” бүлегеннән укучыларга тирән һәм ныклы белем бирү;

- фәнни хезмәтләр белән эшләргә өйрәтү;

- туган төбәккә, аның тарихына, кешеләренә ихтирам , тирән мәхәббәт, горурлык хисләре тәрбияләү;

- укучыларның гомуми үсеш дәрәҗәләрен күтәрү.

Түбәндәге **бурычлар** куелды:

- туган як ономастикасын өйрәнүдә укучыларда кызыксыну формалаштыру, зәвыкларын үстерү;

- үз фикерләрен язма һәм сөйләмә формаларда логик яктан эзлекле, төгәл итеп бирә алу осталыгы һәм күнекмәләре булдыру;

-төрле ялгызлык исемнәренә бәйле чыганакларны үзләштерү максатыннан, фәнн-эзләнү тикшеренү эшләре алып бару;

- фәнни әдәбиятны сайлау, уку - өйрәнү, анализлау, чыганаклар белән эшләргә өйрәтү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

Ономастика өлкәсендә укучыларның киң мәгълумат үзләштерүләренә ирешү;

реферат, сочинение, фәнни –тикшеренү эшләрен яклау, Тау ягы ономастикасы турында мәгълүмат белән башкаларны да таныштыру, презентацияләр, видеофрагментлар әзерләү.

# Тематик план

| № | Эчтәлек | сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр.<br>Борынгы төрки - татар кеше исемнәренең барлыкка килү һәм бирелү мотивлары. Мәҗүси ышануларга һәм йолаларга нигезләнеп барлыкка килгән кеше исемнәре.<br>Антропонимика - исем - фамилияләр турында фән.<br>Антропонимнарның Тау ягы ономастикасында чагылышы<br>Минем исемем һәм туганнарымның исемнәре нәрсәне аңлата? | 2 |
| 2 | Тау ягы кушаматлары. Аларның килеп чыгу тарихы. Кушаматлар – халык тапкырлыгын чагылдыра<br>Нәсел – ыру кушаматлары<br>Шәхси кушаматлар<br>Топоним һәм микротопонимнарга нигезләнеп ясалган кушаматлар.<br>Этнонимнарга мөнәсәбәтле кушаматлар<br>Антропонимнарга мөнәсәбәтле кушаматлар<br>Шәхеснең һөнәр – кәсебе, профессиясе, эшләү урыны белән бәйле кушаматлар.<br>Шәхеснең яки аның ата-бабаларының чины, титулы, социаль чыгышы белән бәйле кушаматлар.<br>Шәхеснең характер сыйфатларын белдерүче кушаматлар.<br>Тышкы физик билгеләрне характерлаучы кушаматлар<br>Хайван, кош – корт, башка тере җан ияләренең исемнәре белән аталган кушаматлар.<br>Кеше гәүдәсе әгъзалары исеме белән бәйлеләре.<br>Мифологик һәм дини терминнарга нисбәтлеләре.<br>Сөйләгән сүзләренә нигезләнеп кушылган кушаматлар.<br>Лексик – семантик мәгънәләрен, барлыкка килү мотивларны билгеләп булмый торган кушаматлар | 4 |
|  | Тау ягы исемнәре, кушаматлары дөньясына сәяхәт: төбәк антропонимнары, аларны классификацияләү.<br>Төбәк антропонимнарын җыю, барлау | 2 |
| 3 | **Гамәли эш.**<br>“Исемең матур- кем куйган?” Минем нәселемдә исемнәр, кушаматлар тарихы, аларның килеп чыгышы һәм мәгънәсе.<br>“Төбәк антропонимнары” презентация ясау, фәнни – эзләнү эшләрен яклау<br>(Эзләнү тикшеренү эше).<br>1- Теоретик материал туплау<br>2- Эзләнү-тикшернү эше | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| 4 | Урта диалектның Тау ягы сөйләшендә “торак пункт” мәгънәсендә йөри торган ойойконимик терминнар, алардан ясалган атамалар . Таулы, калкулыклы җир өстен белдерүче җирле орфографик терминнар һәм географик атамалар.<br>Тигез җир өстен белдерүче җирле орфографик терминнар һәм географик атамалар<br>Түбән, чокырлы, иңкү, уйсу җирне белдерүче җирле орфографик терминнар һәм географик атамалар | 2 |
| 5 | Су чыганакларының исемнәрен туплау, атамаларның килеп чыгышына кагы лышлы материаларны эшкәртү, эзләнү- тикшеренү эшләре алып бару | 2 |
| | **Гамәли эш.**<br>Безнең төбәк чишмәләре, коелары (презентацияләү) | 1 |
| | Минем гаиләм- Ватаным тарихының бер бер өлеше. (Нәселем шәҗәрәсе) | 2 |

Кулланылган әдәбият


1. Әхмәтьянов Р. Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге.. Казан, 2001
2. Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1995.
3. Баскаков Н.А. Русские фамилии тюрского происхождения. - М., 1979.
4. Гарипова Ф.Г. Татарская гидрономия. - Казань, 1998
5. Гарипова Ф.Г. Хәтеремнән чыкмый һич тә. - Казан, 2003
6.
7. Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... - Казан: Тат. кит. нәшр., 1996.
8. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. II том. - Казан: тат.кит.нәшр., 1975
9. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. - Казан, 1981.
10. Саттаров Г.Ф. Исемең матур, кемнәр куйган?, - Казан, 1989.
11. Саттаров Г.Ф. Татар антропонимикасы. - Казан: Тат. кит. нәшр., 1990.
12. Саттаров Г.Ф. Антропонимия Татарской АССР. - Казань, 1975,
13. Саттаров Г.Ф., Вәлиева Ф.С. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. - Казан, 2000

14.Фәхреддинов Р. Г. Болгар вә Казан төрекләре. - Казан: - Тат. кит. нәшр., 1993.

15. https://tatarica.org/tat/razdely/nauka/onomastika

16.http://antat.tatar/ru/iyli/publishing/book/2015/Грамматика_1оптим.pdf